**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, с.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
422870, РТ БазарлыМатакавылы,
С. Крайновур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Базарные Матаки

2024нче елның15ноябре 284№

2024 елның 16 июлендәге
Татарстан Республикасының Әлки
районы Советының
«Әлки муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре,
депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә
гамәлгә ашыручы үзидарәләрнең, рәисләрнең,
контроль-хисап органнары аудиторларының
хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында
Нигезләмәне раслау турында”гы 264 нчы номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

2018нче елның 28нче мартындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең,депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларның, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында”гы 182№ (2018нче елның 24 апрелендәге 281№, 2018нче елның 14нче июнендәге 481№, 2018нче елның 17нче октябрендәге 940№, 2018нче елның 29нчы декабрендәге 1320№, 2021нче елның 17нче ноябрендәге 1087№, 2021нче елның 13нче декабрендәге 1222№, 2022нче елның 17нче сентябрендәге 1015№, 2024нче елның 30нчы апрелендәге 290№, 2024нче елның 24нче июнендәге 451№, от 2024нче елның 25нче сентябрендәге 829№ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), Әлки муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елның 16 нчы июлендәге Әлки районы Советының «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы үзидарәләрнең, рәисләрнең, контроль-хисап органнары аудиторларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау турында»гы 264 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4нче № һәм 5нче № кушымталарны күрсәтелгән împarга яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2025нче елның 1нче гыйнварыннан, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә бер тапкыр исәпләнә, ул 13 990 сум тәшкил итә дип билгеләргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru. рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга .

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны МКО "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы" рәисенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль
районы Башлыгы

А.Ф.Никошин

2024нче елның15нче
ноябрендәге
Әлки муниципаль районы
Советының
284нчы номерлы карарына
4 нче кушымта

**2025 НЧЕ ЕЛНЫҢ 1НЧЕ ГЫЙНВАРЫННАН ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ДЕПУТАТЛАРНЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ҮЗ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ДАИМИ НИГЕЗДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ САЙЛАНУЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ, РӘИСНЕ, КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ АУДИТОРЫН МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК БАШЛЫГЫНЫҢ АЙЛЫК АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8нче төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 37 036 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 33 333 |
| Депутат | 18 162 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 15 432 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 33 333 |
| Контроль-хисап органы аудиторы | 25 461 |

2024нче елның15нче
ноябрендәге
Әлки муниципаль районы
Советының
284нчы номерлы карарына
5нче кушымта

**2025 НЧЕ ЕЛНЫҢ 1НЧЕ ГЫЙНВАРЫННАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР БАШЛЫКЛАРЫН, ДЕПУТАТЛАРНЫ, АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕНДӘ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ҮЗ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ДАИМИ НИГЕЗДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ САЙЛАНУЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ АЙЛЫК АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) | |
|---|---|---|
| | авыл җирлекләрендә | |
| | 10нче төркем | 12нче төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 22 810 | 19 173 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 16 995 | 13 991 |
| Депутат | 13 990 | 13 990 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 13 990 | 13 990 |